№ 35 (1162), 25 август 2012 ел

4 Бердәмлек



сүрәсе, 77 нче аять). «Әл-Мүлк» сүрәсенең 15 нче аятен дә искә алу урынлы: *«Ул (Аллаһ) сезгә җирне йөрергә уңай кылды, ул җир киңлекләрендә йөрегез, теләгән җирендә яшәгез вә җирнең хәләл ризыкларын ашагыз»* диелә анда. Бу дөньяда ни чәчсәң, киләсе дөньяда шуны урачаксың, яхшылыкка – яхшылык, яманлыкка яманлык җимешләрен җыячаксың.

Кеше Аллаһы Тәгалә кануннарын үтәүне үзеннән башлый, үзеннән гыйбрәт ала, үзенә сорау бирә: «Мин кем, нинди нәселдән, кая барам?» Аннан соң үз гаиләсенә, туганнарына һәм башкаларга ислам динен аңлатырга, өйрәтергә тиеш була, һәм бөтен гомере буена шулай яши.

Аллаһы Тәгалә каршында яхшы сүзләрнең иң яхшысы – «Лә иләһә илләл-лаһ, Мөхәммәдүр-рәсүлул-лаһ». Бу сүз – динсез белән дин иясен аера торган сүздер. «Бер Аллаһыдан башка илаһ юк, Мөхәммәд – Аның илчесе» димәктер.

Аллаһы Тәгалә кешеләргә ярдәм йөзеннән, аларны сынау өчен, үзенә чын ихлас белән гыйбадәт кылсыннар һәм адашып йөрмәсеннәр дип, биш төп вазифа йөкләгән. Шушы төп биш вазифа ислам диненең нигезе дип атала:

– чын күңелдән һәм телең белән шәһадәт бирү: «Лә иләһә илләллаһ, Мөхәммәдүр-рәсүлуллаһ»;

– фарыз булган биш вакыт намазны һәр тәүлектә, һичберен калдырмый үтәү;

– байлыгы булган кешегә рамазан-шәриф аенда ярлылар, мохтаҗлар файдасына зәкят садакасын бирү;

– һәр елны рамазан-шәриф аенда бер ай ураза тоту;

– Аллаһы Тәгалә йорты булган Кәгъбәтуллага үз гомерендә бер мәртәбә хаҗ кылу.

Бу биш фарызны үтәү кече гыйбадәт санала. Олы һәм тулы гыйбадәт шушы биш фарызны үтәп, бөтен тереклегеңне һәм тормышыңны бер Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен үткәрсәң генә була.

Аллаһы Тәгалә һәммәбезгә сәламәтлек, хәерле озын гомер, тормышыбызга бәрәкәт, җиңеллек биреп, бөтен гомеребез буена олы һәм тулы гыйбадәт кылып, ике дөньяның рәхмәт-бәрәкәтенә ирешергә һәм җәннәтләрдә күрешергә насыйп әйләсә иде. Амин.

Әлхәмдүлилләһи раббил галәмин.

**Фарук хәзрәт ЗИННӘТУЛЛА.**

# Оялчанлык турында

Оялчанлык, тыйнаклык – кешенең бу сыйфатларын Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә ярата. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: *«Оялчанлыкның нигезе һәм чыганагы – иман»,* – ди.

Һәр диннең әхлак кануннары бар. Ислам нигезендә төп канун – оялчанлык. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм турында сәхабәләре аның тыйнаклыгы, оялчанлыгы саф кызлар оялчанлыгына тиң, ди.

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләре арасында иң оялчаны Госман бин Аффан радыйаллаһу ганһе була. Ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең кияве булса да, мөстәкыйль һәм тыйнак тормыш алып барган. Госман радыйаллаһу ганһенең оялчан, тугры, тыйнаклыгыннан хәтта фәрештәләр дә оялганнар.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләренә киңәш итеп: *«Сез Аллаһыдан тиешенчә оялыгыз»*, – ди һәм аңлатма биреп: *«Аллаһы тыйганнарга бәйле уй һәм ниятне тыю өчен иң беренче Аллаһы Сөбханә вә Тәгаләдән оялырга кирәк»,* – ди. Ягъни Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә рөхсәт итмәгәнгә карамаска, Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә тыйган эш-гамәлләрне кылмаска, сүзләрне тыңламаска һәм сөйләмәскә. Икенче төрле әйткәндә, үз сүзеңә, йөрәгеңә һәм акылыңа хуҗа булып, гөнаһ кылмаска, тыелган (хәрәм) урыннарда йөрмәскә.

Аллаһы Сөбханә вә Тәгаләдән оялган кеше үлем хакында исеннән чыгармый. Көннәрдән бер көнне аның җаны тәнен һәм бу дөньяны ташлап китәчәк. Шуңа күрә ахирәттә бәхеткә ирешү өчен, дөньялыкта Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә биргән мөмкинлекләрне файдаланып калырга кирәк. Бизәнү, байлык, күңел ачу – берничә минутлык күңел теләген (нәфесен) канәгатьләндерүче гамәлләр.

Иманы булган Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә ризалыгы өчен нәфесен тыярга яки бу гамәлләрдән баш тартырга тиеш. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

*«Аллаһы Сөбханә вә Тәгаләдән аның колы курыкмый һәм оялмый башлый икән, Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә ул кешегә кисәтү белдерәчәк. Әгәр ихлас күңелдән учларын күтәреп сорый икән, Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә аның сораганын канәгатьләндерә»,* - дигән.

Оялчанлык башка кешенең оят җиренә карауны тыя. Чит кешеләр бер-берсеннән оят җирләрен капларга тиешләр. Бервакыт Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер сәхабәнең аяклары ачык булуын күрә һәм тиз арада ябып куярга куша, чөнки тәннең бу өлеше мәхрәм һәм аны күрсәтергә ярамый, ди.

Икенче бер очракта Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм оялмыйча урамда юынган кешене очрата да үзе янына чакырып алып: *«Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә оялчан һәм бу сыйфатка ия булган колларын ярата. Оят җирне чит кешегә күрсәтү — килешми торган гамәл»,* – ди. Һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм оят җирләрне күрсәтеп, кеше булган җирдә юынмаска куша. Әгәр дә башка урын юк икән, юынганда оят җирләрне капларга кирәк, ди. Бервакыт ярым шәрә яшьләр Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне күргәч, аннан качалар. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм, Аллаһы Сөбханә вә Тәгаләдән оялмыйча, Пәйгамбәрдән качучы яшьләргә бик гаҗәпләнә һәм оятсызларга һәм башка кешеләргә катгый кисәтү ясый.



Исламда гаилә башлыгы – ир, ул гаиләсен ризык, торак, кием, тәрбия белән тәэмин итә. Хатын-кыз эшли ала, әмма ул эшләргә бурычлы түгел.

2. Дини кануннарны үтәүдә бурыч. Хатын-кыз Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә кушканнарны үтәп, тыелганнан тыелып яшәргә тиеш.

3. Белем алуга бурычы. Хатын-кызның дини һәм дөньяви белем алырга хакы бар. Шулай ук һөнәр үзләштереп, әйтик, укытучы яки табиб була ала.

4. Үз фикерен әйтүгә хокукы. Мөслимәләр, ир-атлар кебек, үз фикерен җиткерергә хокуклы. Моңа мисал итеп Пәйгамбәребезнең тормышын алыйк: көндәлек яки дәүләт эшләрендә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм нинди дә булса карар кабул итәргә җыенганда, хатыннары белән дә киңәшләшкән.

Пәйгамбәребезнең замандаш мөслимәләре активлыклары белән аерылып торганнар. Алар ирләренә ярдәмче дә, гаилә проблемаларын чишкәндә киңәшче дә, үзара мөнәсәбәтләрне җайга сала белгән, гаилә учагын саклаучы асыл зат та булганнар. Хатын-кызның Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә мөрәҗәгать итеп, карар кабул итүгә хокук соравы мәгълүм. Һәм аның хакы турында аять иңдерелә («әл-Муҗәдилә» сүрәсе, 1-3 нче аятьләр; «әл-Мумтәхәна» сүрәсе, 10-12 нче аятьләр). Бу хокук Коръәнгә каршы килми, һәм мөслимә халык алдында җитәкчеләр карарын тәнкыйтьли ала. Гомәр бин Хаттаб: «Гомәр хата ясады, хатын-кыз аның ялгышын төзәтте», – дип әйтеп калдыра.

5. Арадашчылык, килешү төзү һәм мал бүлешү, мөстәкыйль хезмәт итүдә ир белән хатынның тигез хокукка ия булуы.

Ислам күзлегеннән караганда хатын-кыз тормышы, мөлкәте, ирләрнеке кебек үк, кагылгысыз. Һәм нинди дә булса хата, ялгыш адым яки гөнаһ эшләгән очракта җаваплылыкка тарту да һәр җенескә тигез каралган. Әгәр хатын-кызга гаделсезлек күрсәтелә икән, ир кешегә дә мондый очракта тигез (бер дәрәҗәдә) хөкем чыгарыла.

Болардан тыш, Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә ир-аттан аермалы буларак хатын-кызга күбрәк, җаваплырак һәм мөһимрәк бурычлар йөкләгән.

***1. Гаурәтне каплый торган кием кию***

Ислам хатын-кызның инсафлыгын һәм тугрылыгын саклауны кайгырткан. Шуңа күрә кул чуклары һәм йөзне генә калдырып, гаурәтне каплый торган кием кию мәслихәт. Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә шул рәвешле асыл затларны күңелсез хәлләрдән һәм әйләнә-тирәнең тискәре (негатив) йогынтысыннан саклый. Үзенең физик матурлыгын һәм күркәмлеген хатын-кыз ире белән генә бүлешә ала. Ә әйләнә-тирәдәгеләрнең игътибарын җәлеп итүне максат итәргә тиеш түгел ул.

Хатын-кыз мөселманнарның имиджы мәхәббәт, мәрхәмәтлелек, игелек һәм чисталыктан гыйбарәт булырга тиеш.

***2. Җәмәгать намазлары***

Җәмәгать намазында мөслимәләрнең ир-ат артына басуы аларның иреген чикләми. Һәм җәмгыятьтә тоткан урынына карап намазда бүленеш булырга тиеш түгел. Хәтта җитәкче яки ил белән идарә итүче дә намазга басканда гади хезмәткәр янәшәсендә яки аның артына басарга мөмкин. Ирләр белән хатыннарның аерым басуы намаз вакытында Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә хакында фикерләрне чуалтмас өчен һәм чын күңелдән (уй һәм йөрәк белән) Аллаһы Тәгаләгә сыену өчен кирәк. Ир-ат һәм хатын -кыз янәшә баскан очракта, фикерләр чуалып, намаз бозылырга мөмкин.

***3. Мирас мәсьәләсе***

Мөслимәләр гаиләне туендыру өчен яки кемнең дә булса гомерен саклап калу өчен җавап бирми. Бу мәнфәгатьләр тулаем ир-атка йөкләнгән. Әгәр ул ир-ат өйләнгән икән, хатынын, әнисен, кыз туганнарын туендырырга бурычлы. Әгәр хатын-кызның туендыручысы, мирас калдыручысы юк икән, аны хөкүмәт карарга тиеш. Хатын-кыз, ир-ат кебек, мираска хокуклы. Әмма ул (хәнәфи мәзһәбе буенча) мирасны үзе теләгәнчә куллана ала, чөнки хатын-кыз мирасы гаилә бюджеты булып саналмый. Хатын-кыз, ислам дине буенча, әтисеннән бирнә алу һәм үзенә тормыш иптәшен үзе сайлау хокукына ия. Кияүгә чыккач, ире аның милкенә кагылырга тиеш түгел. Кирәк чакта хатын-кызга әтисе (үз баласы буларак) яки ир туганы ярдәм итәргә тиеш. Әгәр мөслимә эшләргә һәм гаиләне туендырырга ярдәм итәргә тели икән, ул бу хокукка ия, әмма үзенең инсафлыгы һәм тугрылыгына хыянәт итмичә.

***4. Шаһитлык мәсьәләсе***

Хатын-кыз шаһитлык кылганда җәмгыятьтәге кагыйдәләргә буйсынып эшләнә. Исламда ике ир кешенең шаһит булуы җитә. Әгәр ир-ат бер генә икән, икенчесе урынына ике хатын-кыз шаһит була ала. Бу хатын-кызны һич кенә дә кимсетү түгел. Гаилә, бала тәрбияләү кебек мөһим бурычлары булганлыктан, хатын-кызның җәмәгать мәсьәләләрендә тәҗрибәсе җитмәскә дә мөмкин.

**Сәрия ЗАКИРОВА.**

*(“Дин вә йола” газетасыннан)*




**- Мөселман гаиләсендә бала туса, аның чәчен һичшиксез алдырырга кирәкме?**

- Чәч алдыру ул – бурыч түгел, ә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәте. Пәйгамбәрнең Ибраһим атлы улы туып 7 көн үткәч, ул гакыйка корбаны чала, балага исем куша. Бала башындагы чәчне кырып ала да садака итеп бу чәч авырлыгында көмеш акча тарата. Пәйгамбәребезнең хәдисендә: «Һәрбер бала өчен гакыйка корбаны бурыч булып тора, шуңа да сабый тугач та, җиденче көндә сарык суегыз, аңа исем кушыгыз һәм аның башындагы чәчен кырыгыз», - дип әйтелә.

*(“Юлдаш” газетасыннан)*